وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# Дин вә Мәгыйшәт

№20 (137). 18 май 2012 / 27-җөмәдел-ахир-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ




Коръәнне тәрҗемә итү мөмкинме?

▷ 2-3 ◁



*Марат НИЗАМОВ:* "Иманнары булмаганнар "хәләл" брендын реклама итеп куллана"

▷ 3 ◁



"Кайсыгызның кулы җылы?" хәйрия акциясе

▷ 4 ◁

## ЯҢАЛЫКЛАР

**"KAZANHALAL 2012" III ХАЛЫКАРА КҮРГӘЗМӘ-ЯРМИНКӘСЕ "КАЗАН ЯРМИНКӘСЕ"НДӘ УЗАЧАК**

2012 елның 19-21 маенда Казан шәһәрендә "KAZANHALAL 2012" III Халыкара күргәзмә-ярминкәсе эшләячәк. Ел саен уза торган хәләл индустрия күргәзмәсе Ислам бизнесы һәм финансларының "KAZANSUMMIT 2012: Россия һәм ислам хезмәттәшлеге оешмасының икътисади хезмәттәшлеге" IV Халыкара саммиты кысаларында үтә.

"KAZANHALAL 2012" III Халыкара күргәзмә-ярминкәсен "Хәләл индустрия милли ассоциациясе" коммерцияле булмаган хезмәттәшлеге ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең "Хәләл" стандарты комитеты белән берлектә оештыра.

Күргәзмә-ярминкәдә катнашу эшлекле мөнәсәбәтләрне җайга салырга, сату базарын киңәйтергә, продукцияне киң җәмәгатьчелеккә һәм сату челтәренә чыгарырга булышачак, Россия һәм дөньядагы башка төбәкләрнең хәләл базары торышы белән таныштырачак.

Күргәзмәнең төп максаты - Россиядә һәм чит илләрдә җитештерелгән хәләл продукцияне һәм төрле хезмәтләрне тәкъдим итү. Хәләл продукцияне мөселманнарга кулланырга яраклы дип кенә түгел, бөтен экология таләпләренә туры килә торган чиста азык-төлек дип күрсәтү бурычы куела. Хәләл - ул азык-төлек кенә түгел, югары сыйфат белән финанс, медицина, туризм өлкәсендә хезмәт күрсәтү дә.

**КОЛ ШӘРИФ МӘЧЕТЕНДӘ КОРЪӘН ХӘТЕМ КЫЛЫНДЫ**

17 майда ТР мөселманнары Диния нәзарәте Кол Шәриф мәчетендә Коръәнне хәтем итүне оештырды. Коръәнне хәтем кылу - Изге Китапны берьюлы тулысынча укып чыгу дигән сүз.

21 майда - Идел Болгарстанында рәсми рәвештә Ислам динен кабул ителгән көндә - Гиннесның рекордлар китабына кертелгән дөньядагы иң зур басма Коръән Казаннан Болгарга күчереләчәк. Хәзерге вакытта ул Кол Шәриф мәчетендә саклана.

**РӨСТӘМ БАТЫР - КОМИССИЯ СОСТАВЫНДА**

ТР Мәдәният министрлыгы мөселманнарның тәкъдимен игътибарсыз калдырмады. Быел Мөселман киносы фестиваленең сайлап алу комиссиясенә дин әһеле кертеләчәк. ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы рәисе Рөстәм хәзрәт Батыр фестивальгә кинолар сайлап алуда катнашачак. Бу хакта 14 май көнне ТР Министрлар Кабинетының киңәшмәләр залында VIII Казан халыкара мөселман киносы фестиваленә әзерләнү һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты уздырган утырышта билгеле булды.

***Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***

**ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙК!**

**2012 елның II яртыеллыгы өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылу дәвам итә. 6 айга язылу бәясе - 118,38 сум.**

# ЯШӘҮ РӘВЕШЕ БУЛАРАК ХӘЛӘЛ

***Әссәламегаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү!***

*Хәзерге вакытта хәләл төшенчәсе киң таралыш тапты һәм аны мөселман оешмалары белән бәйләп карау гадәткә кереп китте. Һичшиксез, моның сәбәбе булып - ислам диненә, мөселман тормышы кыйммәтләренә көннән-көн арта баручы кызыксыну тора. Күпчелек очракта "хәләл"не ашау-эчү, ризык, аерым алганда, билгеле бер хайван итләре, ашамлыкларда "хәрам" категориясенә кергән кайбер кушылмаларның булу-булмавы белән бәйләп карыйлар. Ләкин "хәләл" - киңрәк төшенчә. Ул ашау-эчү, ризык белән генә чикләнеп калмыйча, мөселман кешесенең бөтен тормышын биләп ала. Рөхсәт ителгән һәм тыелганны - хәләл белән хәрамне - Аллаһы Тәгалә кешелеккә эш һәм ниятләр белән тотыру өчен каркас буларак биргән. Шуңа күрә "хәләл", беренче чиратта, үзебезне кайчан-ничек тотуыбызны һәм ниятләребезне билгели торган әхлакый юнәлеш. Кеше нинди генә хәлгә юлыкса да, аның алдында һәрвакыт "хәләл" белән "хәрам" арасында сайлау ирегe торачак - гаиләдәге үзара мөнәсәбәтләр, эштәге хезмәттәшләрең белән аралашу яки буш вакытта уку өчен китап сатып алу һ. б.*

*Коръәндә ачыктан-ачык әйтелгән: "Аллаһ сезгә Үзенең тыйганнары турында төшендерде бит". Галәмне юктан бар иткән Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәү - җәмгыятьне савыктыру юлында әйләнә-тирәне уңай яктан кабул итүгә гарантия. Аллаһы Тәгалә зарар китерүче нәрсәләрне тыйган (бу турыда безне Бар кылучыдан да яхшырак белүче юк). Коръәни-Кәримдә яки пәйгамбәребез (сгв) Сөннәтендә җавап таба алмаслык сораулар юк, шуңа күрә без һәрбер эш-гамәлләребездә, шәригать кануннарына таянып, дөрес юлны сайлый һәм Аллаһы Тәгалә юлынан тайпылмыйча "хәләл"не таба алабыз.*

*Безнең көннәрдә мөселманнар өчен тыелмаган ашамлыкларга хәләл тамгасы сугылган ризык яисә туризм, такси яисә банк картасы кебек тормыш-яшәеш өлкәләре барлыкка килде. Әлбәттә, бу - бер яктан, мөселманнарның тормышын җиңеләйтүче уңай күренеш булса, икенче яктан, Аллаһы Тәгалә рөхсәт итмәгән әйберләрнең әле бу дөньяда күп булуының да күрсәткече булып тора. Безнең өчен тормышыбызның "хәләл" дип аталган Илаһи стандартка туры килүе мөһим булырга тиеш. Шуңа күрә "хәләл" - җәмгыять сәламәтлегенең физик һәм рухи нигезләрен билгеләүче яшәү рәвеше.*

**Үзәкләшкән дини оешма –**
**ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,**
**мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ**

# 21 МАЙ – ИДЕЛ БОЛГАРСТАНЫНДА РӘСМИ РӘВЕШТӘ ИСЛАМ КАБУЛ ИТЕЛГӘН КӨН

**Болгар мохитенә ислам дине үтеп керә башлавы турында мәгълүматлар бик күп. Бәлки, аларның кайберләре дөреслеккә дә туры килә торгандыр. Ә кайберләре дәлилләр, фактлар белән нигезләнгән тәнкыйтькә лаектыр. Болгарстанга мөселман вәгазьчеләре үтеп керү турында шикләнүләр өчен нигез юк. XII йөз авторы Әбу Абдалаһ Гарнати һиҗри ел исәбе буенча тугызынчы елда Мөхәммәд пәйгамбәр Болгарга үзенең өч сәхабәсен җибәрүе турында яза, алар могҗизаи рәвештә ханның авыру кызын терелтәләр һәм Болгарда өч елга калып, мәчет төзиләр һәм ислам динен тараталар. Әлеге сәхабәләрнең берсе Болгарда кала һәм ханның савыккан Туйбикә исемле кызына өйләнә.**

Әмма, кайбер гарәп авторлары хәбәр иткәнчә, аларның кайсы да булса берсенең, Мөхәммәд пәйгамбәрнең төрки телдә язылган хатын алып килеп җиткерүе генә зур сорау булып кала бирә. XIX йөз татар галиме Шиһабетдин Мәрҗани әлеге карашны хуплый, ләкин ул үз фикерен раслау өчен нинди дә булса ышандырырлык дәлилләр китерми. Бәлки, безнең хезмәттә аерым бер фактның ышанычлы булуы алай ук мөһим түгелдер. Бу җәһәттән ислам диненең, дөньякүләм дин буларак, барлыкка килү мизгеленнән Идел буена үтеп керүнең үсеш юнәлешен (тенденциясен) билгеләү мөһим. Моңа мөнәсәбәттә Әбу Гали Әхмәд бине Гомәр бине Рустәнең 903-913 елларда, ягъни Идел Болгарстанында ислам динен рәсми рәвештә дәүләт дине буларак кабул ителгәнчегә кадәр үк язылган "Әл-Әләк әннәфисә" әсәренә кергән мәгълүматлар әһәмиятле. Ул: "Болгарлар - игенчелек белән шөгыльләнә торган халык һәм алар бодай, арпа, тары һәм башка төрле бөртекле культуралар игә. Болгарларның күпчелеге ислам динен тота, авылларда мәчетләр бар, мөәзин һәм имамнар катнашында башлангыч училищелар эшли", - дип яза.

Тулысынча нигезләнгән мәгълүматлар буенча, болгарлар ислам динен әл-Моктадир хәлиф булган вакытта кабул иткәннәр. Шәмсетдин әд-Димәшкигә таянып, XIX йөз дин әһеле Ризаэддин Фәхреддин түбәндәге юлларны язып калдырган: "Болгарлар бердәм дәүләттә яшәгән. Аларның барысы да Моктадир вакытында мөселман булды. Аларның патшалары Моктадирга ислам дине кагыйдәләренә өйрәтү өчен галимнәр җибәрүен сорап үтенеч юллаган. Хәлиф аның үтенечен канәгатьләндергән. Шуннан соң Болгарстаннан хаҗ кылу өчен халык төркеме килә. Аларга мал-туар һәм яшәү урыны белән ярдәм күрсәтелә".

Хәер, ни генә булмасын, Идел Болгарстаны нәкъ менә Айдар (Алмыш) вакытында ислам динен кабул итә. Бу вакыйга ни рәвешле барган соң?

Айдар хан Багдад хәлифенең сарай сәкалибләре башлыгы Нәзир (Нәвир) белән хат алышкан. Ул чыгышы белән Болгардан булган дип уйланыла. Ислам динен дәүләт дине буларак кабул итүне тәмам хәл иткән Айдарның хаты әл-Моктадирга нәкъ менә аның аша тапшырылган. Аны алганнан соң, Багдад хәлифе Идел буе Болгарстанына үз илчелеген җибәрә. Илчелек составында Саусан әл-Раси, Тәкин әл-Төрки, Фарс әл-Сәкалиби һәм илчелек сәркатибе Әхмәд бине Фазлан булган. Хәлиф әл-Моктадир сугыш һәм куркынычсызлык мәсьәләләрендә тулысынча сәкалибләргә һәм төркиләргә ышанган. Делегациянең үзенчәлеге буларак, аның составындагы зур түрәләрнең өчесе чыгышы белән Идел буе төбәгеннән булуын яки аңа турыдан-туры мөнәсәбәттә торуын күрсәтергә мөмкин. Илче Саусан әл-Раси үз вакытында хәлифкә каршы фетнәдә катнашкан булган һәм аны тәхеттән бары тик бер генә көн аерып тора. Аның бабалары Идел буе яклары белән бәйле булган. Тәкин әл-Төрки сәүдәгәр булган һәм тимер белән сату иткән. Ул корал күп җитештерелгән Болгарстан һәм хәлифлек арасындагы мөнәсәбәтләр белән кызыксынуын белдерә.

*(Ахыры 2 нче биттә.)*



# 21 МАЙ - ИДЕЛ БОЛГАРСТАНЫНДА РӘСМИ РӘВЕШТӘ ИСЛАМ КАБУЛ ИТЕЛГӘН КӨН

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

Әлеге фактларны китереп, хәзерге заман гарәп тарихчысы Гадел Совелам Мөхәммәд Гамаледдин сәкалибләрнең кылычлар җитештерүдәге яңалыклары турында язган Әбу әл-Рәйхан Бирунига, һәм болгар биләмәләрендәге коралның күләме вә аларның күп кенә сугышларда катнашу фактларын күрсәткән фарсы авторы әл-Гардизига таяна.

Кыскасы, Идел буе төбәге илчелек әгъзалары өчен таныш җир булган. Профессор Әнәс Халитов билгеләп узганча, IX йөз ахыры - X йөз башында Болгар һәм Багдад арасында урнашкан күптөрле элемтәләр буш урында гына барлыкка килә алмаган. Бу вакытта хәлифәт, галим фикеренчә, күпмедер дәрәҗәдә төркиләрнең көчле тәэсире астында яшәгән. Төркиләр ислам җәмәгатендә дини-хокукый фикердә, фәндә, әдәбиятта түрәләр, гади шәһәр кешеләре, сатучылар һәм сугышчылар кебек үк аның акыл ияләре сыйфатында катнашкан. Төрки отрядлар VIII гасырда Гыйракка, беренчеләрдән булып, габбаси сугышчылары составында килгәннәр, ә Мотасим хәлифә (833-842) вакытында хәлиф гвардиясенең нигезен тәшкил иткәннәр. "Төркиләр ислам өчен терәк һәм хәлифләр өчен таяныч булганнар", "төркиләр бар дөнья буенча да хакимияткә ия булдылар", - дип, Халитов гарәп авторларыннан өзекләр китерә.

Ибне Фазлан күрсәткәнчә, "Габбасилар хәлифәтенә болгар патшасы мөрәҗәгатендә үз төбәгендәге хәрби-сәяси хакимлекне көчәйтү - иң әһәмиятле максат булып торган". Әмма ул хәлифнең бу эштә аңа турыдан-туры ярдәм итә алмавын белгән, чөнки хәлифнең армиясе аңа "аның хәлифәсеннән аерып торучы араның ерак һәм мәйданнарның бик киң булуы" аркасында килеп җитә алмавы турында хәбәр итә. Болгар патшасы сәяси хакимиятнең куркынычсызлыгы билгеле бер чаралар ярдәменнән тыш көчсез булуын аңлый һәм "ул башкача уйлаучы патшалардан имин булу һәм үзенең дошманнарыннан качу өчен крепость төзүләрен сорап" хәлифкә хат яза. Безнең тикшеренүчеләргә билгесез булган күпсанлы фактлар белән эш итүче хәзерге чор гарәп авторлары тарафыннан бу шулай дип язылган.

Илчелек Багдадтан 921 елның 21 июнендә Урта Азия аша юлга кузгала һәм Бөек Болгарга 922 елның 12 маенда килеп җитә. Ибне Фазланның әлеге сәяхәт турында язылган әсәре Идел Болгарстаны тарихын һәм илчелекнең юлы белән кисешкән башка халыкларның тарихын өйрәнү өчен бәһасез чыганак булып хезмәт итә.

Әлеге очракта безнең өчен Идел Болгарстанына илчелекнең ни рәвешле килеп җитүе зур кызыксыну тудыра. Шәһәргә илчелек килеп җитәргә бер тәүлек кала хан аларны каршы алу өчен дүрт кенәзен, шулай ук үзенең ир туганнарын һәм улларын җибәрә. Алар кунакларны кулларында ипи-тоз, ит һәм тары тотып каршы алалар.

Шәһәрдән ерак түгел илчелекне хан үзе каршы алган. Әлеге күренешне Ибне Фазлан менә ничек тасвирлый: "Безне күргәч, ул аттан төште һәм Бөек вә Кодрәтле Аллаһы Тәгаләнең исемен әйтеп, йөзтүбән җиргә капланды. Аның кулында дирһәмнәр бар иде, һәм ул аларны безнең өстебезгә сипте. Ул тирмәләр куярга боерды, һәм без аларга урнаштык".

Хәлифнең хатын укып чыгу мизгеле зур тантанага әверелә. Илчелек тарафыннан алып киленгән ике зур байрак балкып тора, Айдар ханга хәлифтән җибәрелгән ат иярләнә. Илтабарны (болгар башлыгын) хәлифнең югары түрәсе генә кия торган кара киемгә киендерәләр һәм аның башына кара төрбан кидерәләр. Аннан соң барлык катнашучылар да Ибне Фазлан тарафыннан укылган хәлиф хатын тыңлыйлар. Уку тәмамланганнан соң, барысы да бергәләп: "Аллаһу әкбәр!" - дип кычкыралар (Ибне Фазлан бу күренешне "җир селкенеп куйды" дип тасвирлый). Шуннан соң илтабарның әйләнә-тирәсендәгеләр аның өстенә дирһәм сибәләр. Аннары Ибне Фазлан патшага һәм патшабикәгә бүләкләр тапшыра: хушбуйлар, киемнәр, энҗеләр... Аннан соң патшабикәгә мәртәбәле халат кидертә һәм аның өстенә дә хатын-кызлар дирһәм коялар. Шуның белән тантана тәгәлләнә һәм истәлекле вакыйга хөрмәтенә тантаналы кабул итүләр башлана. Илтабар үзе Византия парчасы белән капланган тәхетнең уртасында утыра. Янында - хәләл җефете. Кенәзгә якын торучылар уң якка урнашалар, кунакларны сул якка утырталар. Уллары аның алдында утыра. Ашаганнан соң барлык катнашучылар да чынаяклардан баллы эчемлек - сүҗү эчеп таралышалар. Аннан соңгы көннәр Бөек Болгарда яшәүчеләрне ислам дине нигезләрен өйрәтүгә багышлана. Габдулла исемен алган Айдарның (Алмышның) варислары аның тарафыннан нигез салынган традицияләрне безнең көннәрдә дә дәвам иттерәләр.

**Индус ТАҺИРОВ,**
**тарих фәннәре докторы,**
**Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры**

2012 ЕЛ - ТАТАРСТАНДА КОРЪӘН ЕЛЫ

# Коръәнне тәрҗемә итү мөмкинме?

## (Коръән тәфсире язылганда үтәлергә тиешле шартлар)

**Коръән аңлатмасын (тәфсир) төзүче яки аны башка телгә тәрҗемә итүче нинди сыйфатларга ия булырга тиеш соң?**



Әлеге сыйфатларны санап чыкканчы, Коръәнне сүзгә-сүз (калькалаштырып) тәрҗемә итәргә ярамаганлыгы турында берничә сүз әйтеп узасыбыз килә. Биредә аңлатма бирү, мәгънәгә ачыклык кертү зарур, чөнки ул - Аллаһы Тәгаләнең сүзе. Бар кешелек дөньясы Изге Китапның (яки моңа охшаш китапның) берәр сүрәсенә бәрабәр берни дә иҗат итә алмый.

Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә әйтә: "Колыбызга сәхифәләп (өлешләп) Коръән иңдергәнебездән шикләнсәгез, шуңа охшаш бер сүрә (язып) китерегез вә үзегезне дөресен сөйли торган кешеләр дип уйласагыз, Аллаһтан башка шаһитләрегезне чакырыгыз" ("Бәкара (Сыер)" сүрәсе, 23 нче аять).

Коръәннең үзенчәлеге - бер аятьнең бер-берсенә каршы килми торган бер, ике яки ун төрле мәгънәләргә ия булырга мөмкин булуында. Бу турыда тулырак белергә теләгән кеше Бәйзави тәфсирен ("Әнвар ут-тәнзил вә әсрар ут-тәэвил") укый ала.

Коръән теленең үзенчәлеге - ул үзләренә күптөрле мәгънәләр сыйдырган сүзләрдән төзелгән-оешкан.

Коръән текстының тагын бер үзенчәлеге - анда Пәйгамбәребезнең (сгв) үзе тарафыннан бирелгән аңлатмалар таләп ителә торган урыннар да аз түгел, чөнки моннан башка аларны бүтәнчә аңларга мөмкин. Аллаһ Илчесе (сгв) кешеләргә Коръәнне аңлатучы төп мөгаллим булып кала.

Коръәндә төрле очракларга яки урынчалыкка таянып, кешеләрнең тормышы һәм көнкүрешенә бәйле сорауларга җавап кебек иңгән аятьләр дә бихисап. Әгәр дә Коръәнне очрагына туры килгән хәлләрне белмичә тәрҗемә кылсаң, кешеләр ялгыш фикерләргә юлыгачак.

Шулай ук Коръәндә иман, Ислам, Аллаһның сыйфатлары, күкләр һәм җирләр, хокук, канун, тарих, гореф-гадәтләр һәм гарәп теленең сүз сәнгате (красноречие) фәннәре белән бәйле аятьләр бар. Әгәр дә галим кеше (гарәп телен никадәр камил дәрәҗәдә белгән хәлдә дә) югарыда телгә алынган фәннәр буенча мәгънә эчтәлеген бирә алмаса, ул, аятьнең бар тирәнлегенә төшенә һәм аны шул дәрәҗәдә аңлата алмаячак. Менә ни өчен Коръәнне сүзгә-сүз тәрҗемә итү мәгънәсез гамәл булып тора. (Хәзерге көндә рус телендәге тәрҗемәләрнең барысы да сүзгә-сүз тәрҗемәләрдән санала.)

Шул сәбәпле, Коръәнне аңлатма бирүдән тыш тәрҗемә итәргә ярамый. Аңлатма (тәфсир) төзү өчен билгеле бер кагыйдәләрне үтәргә кирәк. Коръән тәрҗемәсендә яки аның тәфсирендә әлеге таләпләрнең берсе генә сакланмаган очракта да, бу җаваплылыкны үз өстенә алган зат (шәхес) үзе дә ялгышачак һәм башкаларны да ялгыш фикерләргә кертеп җибәрәчәк.

Хәзер Коръән тәфсирен (ягъни аңлатмасын) төзүче ия булырга тиеш шартларны санап узыйк.

1. Ул гарәп телен һәм аның семантикасын (мәгънә катламнарын) камил дәрәҗәдә белергә тиеш. Шул сәбәпле, телне белмәгән кешегә тәфсир төзү эшенә алынырга ярамый. Ул камил дәрәҗәдә гарәп теленең грамматик төзелешен белергә тиеш. Гарәп телендә һәр сүзнең мәгънәсе хәтта хәрәкәләр үзгәргән саен алмашына.

2. Берничә телнең сарыф фәнен (морфология һәм сүзләрнең төрләнешен) камил дәрәҗәдә белү зарур. Ягъни һәр сүзнең нигезен, сүз ясалышын, форма ягыннан мәгънә үзгәрешен белергә кирәк. Боларның барысын да белми торып, бөтен Коръәнне ялгыш аңларга мөмкин.

3. Ул этимология (сүзләрнең килеп чыгышы; гарәпчә - гыйльмел иштикак) фәнен төпле итеп үзләштергән булырга тиеш. Әгәр дә ике тамырдаш сүз булса, аларның мәгънәсе сүзнең нигезе буенча карала.

4. Семантиканы (лингвистика фәнендә тел берәмлекләренең мәгънәсен өйрәнүче махсус бүлек; гарәпчә - мәган) белергә кирәк. Бу аңа сүзнең оешуы буенча мәгънәсен аңларга мөмкинлек бирәчәк.

5. Шулай ук камил дәрәҗәдә стилистиканы (иң кимендә ике телнекен; гарәпчә - гыйльмел бәян) да белергә кирәк. Бу - җөмлә төзелеше үзенчәлекләре һәм аларның үзгәрешләре буенча сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәләрен аңларга мөмкинлек бирәчәк.

6. Риторика (гарәпчә - бәләгать) фәнен белергә кирәк. Бу - сөйләм дәрәҗәсендәге осталыкны ачарга ярдәм итәчәк.

Алда әйтелгән өч фәнне Коръән тәфсире төзергә яки Коръәни-Кәримне тәрҗемә кылырга җыенганнарга белү мәҗбүри. Әлеге фәннәрне белмәгән кеше Коръән теленең камил ритмлы, искиткеч бай һәм аһәңле булуын аңлый алмаячак. Әлеге фәннәрне үзләштергән кеше Коръәннең могҗиза, Аллаһ сүзе булуын аңлый да алыр, һәм бар кешелек дөньясының моңа охшаш әсәр тудырырга сәләтсез икәнлегенә төшенер!

Пәйгамбәребез (сгв) заманында гарәп теленең сүз сәнгате (красноречие) иң югары баскычта булган, һәм ул вакытта яшәгән гарәпләр Коръән сүзенең мәгънәви тирәнлегенә һәм гүзәллегенә таң калганнар, шулай ук, кешенең моңа охшаш китап барлыкка китерә алмаячагын, монда Аллаһның кодрәте булуын аңлаганнар. (Аллаһның Китапларына (Тәүрат, Зәбур, Инҗил, Коръәни-Кәрим) ышану - иман шартларыннан санала.) Шуны аңлау аша гарәпләрнең күпчелеге Коръәнне таныган, әмма дан-шөһрәткә һәм байлыкка алданучыларның кайберләре аңа ышанудан баш тарта. Шуннан соң алар үзләре нәрсә дә булса иҗат итәргә омтылыш ясап карыйлар, әмма Коръәни-Кәримгә охшаш өч кенә юл да яза алмыйлар.

Бүгенге көндә Коръән текстын тәрҗемә итү белән шөгыльләнергә җөрьәт итүчеләр югарыда саналган фәннәрне бөтен камиллегендә белми диярлек.

7. Коръәнгә аңлатма бирүче һәм тәрҗемә итүче аны уку алымнарын һәм кагыйдәләрен (кыйраәт) белергә мәҗбүр. (Коръән укуның җиде төрле алымы бар.)

8. Гакыйдә (инану нигезләре) нык үзләштерелгән булырга тиеш. Киресенчә булган очракта аңлатма бирүче мәгънәви тәрҗемә башкара алмаячак, һәм үзенең сүзгә-сүз тәрҗемәсе белән үзе дә ялгышларга күмеләчәк һәм башкаларны да гөнаһка алып керәчәк.

9. Тәрҗемә итүче, аңлатма бирүче Коръәннән ничек итеп хөкемнәр чыгарылуы турында сөйләүче ислам юриспруденциясен, ислам хокукын (фикъһе, ысул) төпле итеп белергә тиеш. Әлеге фәннәрне белми торып, ул Коръәннән искәрмәләр һәм дәлилләрнең ничек чыгарылганлыгын белмәячәк.

10. Шулай ук фикъһене, ягъни Шәригать фәненең үзен белү кирәк. Әлеге фәнне белмәгән кеше, ялгыш аңлатмалар китереп, Шәригатьне бозып күрсәтәчәк.

11. Аятьләрнең иңү сәбәпләрен һәм нәтиҗәләрен белергә кирәк. Аларны белмичә торып, билгеле бер (конкрет) сәбәпләр белән бәйле булган аятьләрнең мәгънәләрен аңлау мөмкин түгел.

12. Ул нәсих-мәнсухны, ягъни моннан алдагы аятьнең нәтиҗәсен шуннан соңгы кайсы аять кире кагуын, һәм аларның кайсына таянырга, кайсы артыннан барырга икәнлеген белергә тиеш. Мисал өчен, бер аять тол хатынның кабаттан бер ел дәвамында кияүгә чыга алмавын әйтә, ә башка бер аятьтә дүрт ай да ун көн көтеп торырга кирәк булуы әйтелә. Әгәр дә тәрҗемәче нәсих-мәнсухны белмәсә,

тәрҗемә кайсы аятькә иярергә кирәк икәнлегенә ачыклык кертмәячәк.

13. Тәрҗемәче мәгънәсе үзеннән үзе аңлаешлы булмаган, кыска иңдерелгән аятьләрнең мәгънәләренә ачыклык керткән хәдисләрне белергә тиеш. Ул гарәп телен ничек кенә яхшы белсә дә, әлеге аятьләрнең мәгънәсенә ачыклык керткән хәдисләрдән тыш, башка кеше аңларлык тәрҗемә ясый алмаячак.

14. Коръәнгә аңлатма бирүче, тәрҗемә итүче "ладуни гыйльменә" - Коръәнгә һәм хәдискә ияреп баруның соңында аңа Аллаһ тарафыннан ачылган яшерен белемнәргә ия булырга тиеш. Хәдистә әйтелгән: "Алган белемнәре буенча баручы кем генә булмасын, Аллаһ ул кеше белмәгән фәннәрне дә аңа ачачак" (Әбу Ногайм). Коръәнне рус теленә тәрҗемә итүчеләрнең берсе генә булса да әлеге шартларны үтәгән булып торамы? Юк, берсе дә.

Безнең чор дин галимнәре әйткәнчә, югарыда китерелгән барлык фәннәргә өстәп, Коръән тәфсирен төзүче яки тәрҗемә итүче табигать фәннәрен дә белергә тиеш. Коръәндә бары тик соңгы гасырларда гына галимнәр аңлатмалар тапкан ачышларга күрсәтә торган аятьләр шактый күп. Ундүрт гасыр элек иңгән Коръәни-Кәримдәгеләр кеше тарафыннан уйланган әсәр түгел, бу - Аллаһы Тәгаләнең Сүзе икәнлеген тагы бер тапкыр раслый торган нечкәлекләр дә бар.

Коръән аңлатмасы язарга яки аны тәрҗемә итәргә алынучының әлеге таләпләргә туры килүе зарур. Моннан тыш, Коръәнне тәрҗемә итүче түбәндәге шартларга да җавап бирергә тиеш:

1. Гарәп теле белән беррәттән ул тәрҗемә итеплә торган телне дә бертигез дәрәҗәдә белергә тиеш. Коръәнне аңлау - бер нәрсә, ә аны башка телгә тәрҗемә итү - ул үзе янә бер җаваплы хезмәт. Шунлыктан, ике телне дә камил дәрәҗәдә белү таләп ителә.

2. Ул иң әүвәл Коръән тәфсирен гарәп телендә язарга тиеш. Аннан соң тәфсирнең мәгънәсен тәрҗемә итәргә дә мөмкин булачак. Шул рәвешчә, укучы моның сүзгә-сүз тәрҗемә түгел, ә аңлатма икәнлеген беләчәк. Коръәннең сүзгә-сүз тәрҗемәсе була алмый.

3. Коръәнне тәрҗемә итүче тәкъва кеше булырга тиеш. Әбу Бәкер (Аллаһ аннан разый булса иде): "Әгәр Коръәнгә һәм хәдискә каршы килерлек нәрсә дә булса эшләсәм, мине нинди җир күтәреп торачак?" - дип әйткән. Мондый тәкъвалыкка ия булмый торып, тәрҗемәче үзенә нәрсә ошаса, нәрсә җиңел бирелсә - шуны язарга мөмкин.

Барлык ислам галимнәре дә килешә төшәләр: Коръәнне тәрҗемә итеп аның тәфсирен төзү өчен югарыда безнең тарафтан саналган шартларны төгәл үтәргә кирәк. Боларның барысын да җентекләп өйрәнергә теләгән кеше түбәндәге китапларны укый ала: Җәләлетдин әс-Сөюти "Әл-Иткан фи үлүм әл-Коръән"; Сәйид Галәви "Әл-Кәваидел әсасият фи үлүмил Коръән"; Мөхәммәд Зөбәйди "Итхаф"; доктор Нуреддин Гитр "Үлүмүл Коръәнил-Кәрим" һ. б.

**Нияз САБИРҖАНОВ**

# Марат НИЗАМОВ: "Иманнары булмаганнар "хәләл" брендын реклама итеп куллана"

**Татарстанда хәләл ризыкка ихтыяҗ һәрвакыт зур булды. Хәзер бу ихтыяҗ көннән-көн үсә һәм "хәләл" дип аталган тулы бер индустрия барлыкка килде. 2005 елда "хәләл" тармагына булышу, хәләл товарларны җитештерүгә һәм таратуга күзәтчелек итү максатыннан Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте каршында "Хәләл" комитеты булдырылган иде. Комитет җитәкчесе Марат Ренат улы Низамов оешманың бүгенге эшчәнлегенә кагылышлы сорауларга җавап бирде.**




***- Марат әфәнде, Диния нәзарәтенең "Хәләл" комитеты "хәләл" стандартын билгеләүдә бары тик үзе генә эш алып барамы, әллә башка оешмалар да катнашамы?***

- "Хәләл" комитеты продукт сыйфатын һәм аның шәригать нормаларына туры килүен республиканың "Тест-Татарстан" сертификация-методик үзәге белән берлектә тикшерә. Бүгенге көндә рәсми көчкә ия "хәләл" стандарты системасы комитет һәм "Тест-Татарстан" оешмасы хезмәткәрләре белән берлектә эшләнде. Безнең комитет хезмәткәрләре шәригать нормалары үтәлүне, ә "Тест-Татарстан" хәләл продукт җитештерүнең технологик ягын күзәтүне җайга салды. Әлеге оешма вәкилләре ГОСТларны тикшерү буенча эшләгәннәр, аларның технологик белемнәре һәм бу өлкәдә тәҗрибәләре бар.

***- Димәк, нинди дә бер товарда Диния нәзарәтенең "Хәләл" билгесе тора икән, бу комитет белән хезмәттәшлек итүче оешманың да сыйфат билгесе дигән сүз?***

- Әйе, сертификатта бу хакта әйтелә. Без беренчел тикшерүләрне үткәрәбез һәм таныклык бирәбез, ә алар - сертификат бирә. Сертификат таныклыктан башка рәсми көчкә ия түгел. Ягъни, әгәр кем булса да таныклык алып сертификатны узмаган икән, аның таныклыгы 30 көннән соң үз көчен югалта. Мондый тәртип үзара килешеп, бергәләп эшләнде. Шуңа күрә икеләтә контроль килеп чыга. Беренчесе - дини, икенчесе - технологик җитештерүгә, санитар нормаларга кагыла.

***- Сертификат алу һәр җитештерүче өчен мәҗбүри түгел. Алар бары тик үзләре теләп кенә "хәләл" стандартын тапшыра. Әкиләчәктә теләк белдерүчеләр күбәер дип фаразлый алабызмы?***

- Берсүзсез, "хәләл" сертификатын алырга теләүчеләр тагын да артачак. Бу төр базар зурая. Әгәр дә биш ел чамасы элек аерым кибетләр, кафелар, кечкенә цехлар булса, бүгенге көндә хәләл индустрия ул - зур кошчылык фабрикалары, заводлар һәм башкалар. Бу өлкә азык-төлеккә генә кагылмый, хәтта хәләл косметика, хәләл кунакханә бизнесы, хәләл таксилар барлыкка килә.

***- Алайса "хәләл" сертификаты эшмәкәрләрне шактый кызыксындыра?***

- Бүгенге көндә "хәләл" бренды бик популярга әйләнде. Аның сыйфат билгесенә тәңгәл килүе турында күп язалар, сөйлиләр. Хәләл икән, димәк зыянлы өстәмәләр юк, сәламәт мал ите... Бүген теләсә кайсы базардагы ит киштәләренә гадәти картон кәгазьләргә "хәләл" дип язып куялар. Кайберәүләрнең "хәләл" брендыннан бары файда күрергә омтылуын белеп торырга кирәк. Бу проблеманы хәл итүдә дәүләт тарафыннан да чаралар күреләр дип уйлыйм. Мәсәлән, безгә "хәләл" ярлыкларының чынбарлыкка туры килүен тикшерүне сорап Әлмәттән мөрәҗәгать иттеләр. Кызганыч, гаделсез җитештерүчеләр бар. Мондый хәлләр бренд дәрәҗәсен төшерә. Күптән түгел без Самарадан килгән вәкилләр белән очраштык. Алар ит базарларында хәләл итне дуңгызныкы белән бергә куярга яки хәләл продукт сатыла торган җирдә алкоголь тәкъдим итәргә мөмкин булулары турында сүз кузгатты. Күңелләрендә иман, Аллаһка ышану булмаганнар "хәләл" сүзен реклама рәвешендә кулланып, башкаларның ихтыяҗыннан үзләренә файда күрергә ашыгалар. Әгәр дә иртәгә башка әйбер популярлашса, алар шуңардан файдаланырга тырышачаклар. Шуңа күрә сертификат алырга теләүчеләр күп, әмма моның өчен башта куелган таләпләргә туры килгән җитештерүне будырырга кирәк.

***- Шәһәрдә хәләл ризык ашатыла торган балалар бакчалары, мәктәпләр бар. Балаларга хәләл ашату хокукын алу ничегрәк тормышка ашырыла? Бу мәсьәләне хәл итүдә Сезнең комитет катнашамы?***

- Андый мәктәпләр бар, әмма без алардагы ризыкның чын сыйфаты өчен җавап бирә алмыйбыз. Без бу эш белән шөгыльләнергә телибез. Мәктәпләрне ризык белән тәэмин итү буенча тендер отучыларга күзәтчелек итсәк, ышаныч артыр иде. Әлегә бу катлаулы сорау булып кала. Ата-аналарга дөрес, тулы мәгълүмат тарату да мөһим. Чөнки күпләре хәләлне ниндидер бер "сакраль" ризык итеп кабул итә. Хәләл ризыкның чынлыкта ни икәнен аңлатырга һәм мәгълүмат бирү өчен дин әһелләрен генә түгел, табибларны да җәлеп итәргә кирәк. Безнең бит медицина университетында сәламәт туклану кафедрасы бар.

***- Билгеле булганча, Универсиада вакытында анда катнашучылар үзләренә хәләл ризык төрен сайлый алачак. Комитет бу уңайдан ниләр башкара?***

- Без бу мәсьәлә буенча актив рәвештә шөгыльләнәбез, махсус программалар эшлибез һәм хөкүмәткә хатлар юлларга җыенабыз. Монда бик күп өлкәләрне: азык-төлек белән тәэмин итү, катнашучыларны намаз укый алырлык урыннар булдырып урнаштыру, хәләл ял һ. б. искә алырга кирәк. Боларны хәл итүдә иницитива күрсәтергә ниятлибез.

***- Көннәр җылытуга урам кафелары саны арта. Алар арасында мөселманнар иркенләп утырып туклана алырдайлары булырмы? Икенче төрле әйткәндә, җәйге кафе хуҗаларыннан мөселманнар өчен шартлар тудыруны көтәргә кирәкме?***

- Әйе, андый төрдәге җәйге хәләл кафе ачучылар булыр дип уйлыйм. Без хезмәттәшлеккә һәрвакыт әзер.

***Комитет турында бар мәгълүматны www.halalrt.com сайтыннан табарга мөмкин.***

# Хөтбә-вәгазьләр тарихыннан

**Инсаниятта тел гаять тылсымлы, кодрәтле көчкә ия. Элеккеге заманнарда ук акыл ияләре, олуг әдипләр бу көчнең бөеклегенә, нәфислегенә сокланганнар, аның җәмгыятьтә тоткан урынына олы бәһа биргәннәр.**

Әйе, тел - фани дөньяны, чынбарлыкны танып белү, аралашу-фикерләшү, инсанияt тудырган матди һәм мәдәни кыйммәтләрне алдагы буыннарга тапшыру чарасы гына түгел, ул - куәтле ышандыру һәм инандыру коралы да.

Телнең тылсымлы тәэсир итү көче, барыннан да бигрәк, аның кешеләрнең аңына, хис-тойгыларына, эчке кичерешләренә зур йогынты ясавында. Ә бу исә, үз нәүбәтендә, күп төрле алымнар, тел-стиль чаралары аша тормышка ашырыла.

Борынгы Грециядә, Римдә, Һиндстанда матур сөйләм сәнгате аерым фән буларак үскән. Ул заманнарда ук дөрес, төгәл, ачык һәм нәфис сөйләмне барлыкка китерә торган чараларны өйрәнгәннәр, матур сөйләм сәнгатенә өйрәткәннәр, оста оратор-нотыкчылар тәрбияләүгә җитди игътибар биргәннәр.

Элек-электән үк татар мәктәп-мәдрәсәләрендә дә, исламият кануннарын ныклап үзләштерү белән берлектә, сүз сәнгатенә, сөйләшү әдәбенә дә өйрәтелгән, ораторлык сәнгатен үзләштергән һәм Аллаһ сүзен, Мөхәммәд пәйгамбәр хәдисләрен хәляикъка фәһемле, оста җиткерә белүче имам-хатыйблар хәзерләүгә зур урын бирелгән. Сөйләшә белү, сүз сәнгатенә ия булу иң мәртәбәле һәм иң кирәкле гамәлләрнең берсе итеп саналган. Шунлыктан дини уку йортларында төп фәннәр булган Коръән, тәҗвид (Коръәнне дөрес итеп уку турындагы кагыйдәләр - Ф.М.), Коръән тәфсире (аңлатмалары), гакаид (иман), фикъһе (ислам дине мәсьәләләре турындагы белем), Ислам һәм пәйгамбәрләр тарихы, шәригать гыйлемнәре, гарәп телен өйрәтүдән тыш, әхлак, риторика, фәлсәфә, мантыйк (логика), психология, педагогика, фәраиз (мирас кагыйдәләре) кебек гакылият фәннәре дә укытылган.

Дөрес, ул вакытларда төрки-татар телен өйрәтүгә тиешле игътибар булмаган, чөнки барлык дини йолалар да, нигездә, гарәп телендә башкарылган. Әмма татарча уку һәм төрки текстларны өйрәнү, фикерне үстерү, телне шома, уйны йөгерек итеп әйтә белү, ирекле әңгәмәгә һәм мөназарәгә (бәхәскә) хәзерләү буенча да дәресләр, гамәли шөгыльләр үткәрелгән. Шул максаттан Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф", Борһанетдин Рабгузиның "Кыйссасел әнбия", Сөләйман Бакырганиның "Ахырзаман китабы", "Бәдәвам", "Кисекбаш", Таҗетдин Ялчыголның "Рисаләи Газизә", Мөхәммәд Чәләбинең "Мөхәммәдия", Суфи Аллаһиярның "Сөбател-гаҗизин" һ. б. китаплары файдаланылган. Мәхмүд Болгариның "Нәһҗел Фәрадис", Мәҗлисинең "Кыйссаи Сәйфелмөлек", Өмми Камал, Сәйф Сараиның "Гөлстан бит-төрки" һ. б. әсәрләрнең кулланылганлыклары да мәгълүм.

Әйткәнебезчә, дини йолаларны башкару, җомга һәм гает намазлары һәм анда укыла торган хөтбә-вәгазьләр дә гарәп телендә алып барылган. Чөнки Изге Коръәнне, пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) сөннәтләрен башка бер телдә сөйләү-аңлату гөнаһлардан саналган.

Әмма XIX йөзнең ахырларында бу мәсьәләдә вәзгыять үзгәрә башлый. Ул татар халкының милләт булып формалашу, милли әдәби тел барлыкка килү, милли үзаң үсү, тәгълим-тәрбия системасында җәдиди үзгәрешләр башлану белән бәйләнгән. Мөселман татарларга Ислам кануннарын, дини йолаларны яшәеш өчен файдалы булырлык итеп үз ана телендә, халык сөйләмә теленә якын булган аңлаешлы телдә өйрәтү, аңлату мөһим мәсьәләләрнең берсенә әверелә.

Кайбер мәгълүматлардан бәян булганча, аларны гамәлгә ашыру XX йөзнең башларына туры килә. Татарча хөтбә укуны башлап җибәрүчеләрнең берсе "Иж-Бубый" мәдрәсәсенең имам-хатыйбы һәм мөдәррисе Габдулла Нигъмәтуллин-Бубый була. 1906 елның 21 мартында хаж сәфәреннән әйләнеп кайткан Габдулла Бубый җомга хөтбәсен татарча укый. Бу - бөтенләй башка килмәслек вакыйга була. Күп төрле шау-шулар, каршылыклар, аңлашылмаучылыклар булуга карамастан, абруйлы, уй-ниятләренә инанган тәвәккәл кеше буларак, ул башлаган эш-гамәлләреннән чигенми; җомга һәм гает хөтбәләрен ана телебездә укуын дәвам иттерә. 1908 елда аның "Татарча хөтбә уку дөрестме?" дигән китабы нәшер ителә. Ул анда Коръәнгә, пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) хәдисләренә, атаклы дин галимнәренең хезмәтләренә нигезләнеп, үз фикерләренең дөресле-

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# Ислам мәгарифенең әһәмияте, аның хәзерге торышы һәм киләчәге

*(Дәвамы. Башы газетабызның 11 май (№ 19) санында.)*

XVII-XVIII йөз чикләрендә мөселман укымышлылыгының яңарышы күбесенчә чит илләрдә укыган яки мөселман илләреннән чыккан татарларга бәйле рәвештә барлыкка килгән. Мәшһүр татар мәгърифәтчеләре Ризаэддин Фәхреддин белән Шиһабетдин Мәрҗани китап укымышлылыгын беренчеләрдән булып кайтаручы дип Оры (хәзерге Арча районында. - ред.) авылыннан Юныс бине Иванайны атый, ул Мавәраэннәһердә (Төркестан. - ред.) белем алган. Укып кайтканнан соң, Ю.Иванай мәдрәсәгә нигез сала һәм гарәп теленнән башлангыч белемнәр алу өчен кирәк булган "Бидан" китабына (гарәп теле сүзләренең килеп чыгышы буенча язылган хезмәт) аңлатмалар бирә.

Р.Фәхреддин раслаганча, Казан ханлыгы алынганнан соң халыкның бер өлеше Кырымга, Төркиягә һәм Дагстанга качкан. Берникадәр вакыттан соң алар өйләренә кайтканда үзләре белән кайбер китапларны һәм иҗат әсәрләрен алганнар. Р.Фәхреддин, иң башта ук (Казан ханлыгы алынганнан соң) татарларның бабалары Дагстанда һәм Бохарада гыйлем эстәгән, дип әйткән булган. Моннан тыш, татар мәгърифәтчесе фикеренчә, Дагстанда уку зур файда китергән булса, Бохарада белем алу тиздән файдасыз һәм зыянлы булып чыга. Р.Фәхреддин исәпләгәнчә, 1552 елдан соң төрки телле мөселманнар ислам китабы культурасы нигезләрен югалтканнар. Дагстан голәмәләренең төп казанышы булып, хокук, хәдис белеменә кереш, риторика, нәһү (синтаксис) һәм сарыф (морфология) кебек фәннәрдән белем бирү торган. Нәкъ менә алар үзләренең укучылары белән татарлар арасында мәдрәсә мәгарифе системасын торгызганнар. Дагстан галимнәреннән Р.Фәхреддин Мөхәммәд бине Гали әд-Дагстанины, Мөхәммәд бине Муссу әл-Кадыки әш-Ширванины (якынча 1725-1726 елларда вафат була) искә ала. Соңгысы, аның сүзләренчә, Болгар белән Казаннан шәехләр силсиләсе башланып киткән суфи булган. Тагын бер остазы итеп ул Мортаза бине Котлыгыш әс-Симетине (1723 елда дөнья куя) атый, монысы исә Дагстанда белем алып, туган ягына кайта һәм Мамадыш өязендә мәдрәсә төзи, үзеннән соң күпсанлы укучылар калдыра...

Ш.Мәрҗани, Дагстанда белем алган һәм сизелерлек йогынты ясаучылардан өч голәмәне билгеләп уза. Алар арасында Оренбург янындагы Кондырау авылында укыткан Мөхәммәд әд-Дагстани, Мәчкәрә авылында (хәзерге Кукмара районында. - ред.) белем биргән Мөхәммәдрәхим бине Йосыф Ашыти-Мәчкәрәви (1818 елда үлә), шулай ук беренче Казан мәхәлләсе ахуны Ибраһим Хуҗаш әл-Казани (1825 елда ахирәткә күчә) да бар. Әд-Дагстаниның укучысы - булачак мөфти Мөхәммәтҗан Хөсәен (1756-1824), М.Ашытиның шәкерте хәтта Габденнасыйр әл-Курсави булган. И.Хуҗаши мәдрәсәсе программасында әлифба, иман шарты, нәһү (синтаксис), сарыф (морфология), мантыйк (логика), гакыйдә (догматика), тәфсир, гыйльме фарыз (милек бүлеге), астрономия һ. б. фәннәр булган.

Әлеге программаның эчтәлегеннән чыгып, Оренбург мөселманнары Диния нәзарәте төзелгәнче дини мәгариф системасы анык структура булмаган, дигән фикер калырга мөмкин. Гарәп әлифбасы фәне белән беррәттән, мантыйк (логика) һәм тәфсир кебек катлаулы дисциплиналар да булу - башлангыч (мәктәп) һәм тирәнәйтелгән (мәдрәсә) төркемнәренә бүленешнең булмавы турында сөйли. Әмма нинди генә очракта да профессор Айдар Хәбетдиновның фикере белән килешмичә мөмкин түгел: "Кавказда белем алучылар XVIII гасырда Казан артында һәм Урал буенда классик мөселман мәгарифе һәм суфичылык яңарышына һәм үсешенә шактый зур йогынты ясаганнар. Без Диния нәзарәте оешканчы һәм Бохара өстен булганчыга кадәр үк мөселман мәгарифенең яңарышы турында сүз алып бара алабыз". Кайбер мәгълүматларга караганда, 1800-1860 елларда хәзерге Башкортстан территориясендә эшләгән һәм чит илләрдә белем алган мөгаллимнәрнең саны 21,5 %, ә 1860-1890 елларга таба 13,4 % булган. Әлеге процентның кимүе бездә мәгариф системасының зур үсеш алуын күрсәтә.

**(Ахыры бар.)**

**Марат хәзрәт МӘРДАНШИН,**
**тарих фәннәре кандидаты**

# Хөтбә-вәгазьләр тарихыннан

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

ген дәлилли. "Вәгазь, - ди ул, - җыелган халык Ислам һәм милли рух белән сугарылсын, киләчәктә һәм мәңгелек яшәештә үзләренә файда китерерлек нәрсәләрне аңласыннар өчен кирәкледер. Татарларның күпчелеге гарәп телен аңламыйлар, атна саен бер үк нәрсәне сөйләүче имамнар да мәгънәсенә төшенмиләр. Әгәр кешеләр нәрсә турында сүз баруын аңламыйлар икән, моны хөтбә дип исәпләргә мөмкинме?"

Татар телендә хөтбә укуга бик күп каршы торучылар булса да, аның башлангычын куәтләүчеләр дә табыла. Шул уңайдан "Йолдыз" газетасында татарча хөтбә укуны хуплаган мәкалә дә дөнья күрә. Кызганычка каршы, бүгенге көннәрдә шактый гына мәчет-мәдрәсәләрдә, җәмәгать җыеннарында хөтбә-вәгазьләр рус телендә алып барыла. Гарәпчә дә түгел, татарча да түгел, ә ят рус телендә. Заманның иң көйсез, гаять шаукымлы вакытларында да бу хөтбә-вәгазьләрнең илаһи көчен, әһәмиятен аңлаган мөхтәрәм Габдулла хәзрәтләре татарча нотыклар сөйләгән, бар җыелган гавамны авызына каратып тоткан бит! "Замане иҗтиһад мөнкаризмы, дәгелме?" ("Иҗтиһад заманы юкка чыкканмы, түгелме?") дигән хезмәтендә дә Г.Бубыйның бу реформаторлык фикерләре дәвам иттерелә .

Шулай итеп, Г.Бубый татарлар арасында Ислам дине тәгълиматын вәгазьләүгә, пропагандалауга зур өлеш кертә. Җәдитчелек тарафдары буларак, ул Исламны киң халык массаларына аңлаешлы булган татар телендә аңлатуны яклый, шулай иткәндә, кеше аңына әйбәтрәк йогынты ясау мөмкинлеген күрсәтә. Шул рәвешле ул җомга һәм гает намазларында татарча хөтбә укуны нәзари яктан дәлилләп бирә. Бер үк вакытта Г.Бубыйның хатыйблык осталыгы турында да әйтеп узасы килә. Юкса, Мәкәрҗә ярминкәләренә кадәр барып җитеп, бай татар сәүдәгәрләрен мәдрәсәнең хәйрия фонды өчен "юмартланырга" күндерә алмас иде. Заманында "Иж-Бубый" мәдрәсәсен тәмамлаган һәм шунда татар теле мөгаллиме булган Җамал Вәлиди дә үзенең остазы турында болай дип язган: "Җанлы, үткен, ялкынлы кеше иде. Адымнарын тәрәддедсез (икеләнүсез - Ф.М.) атлый, фикерләрен ачык, кискен йөртә. Аның табигатендәге тизлек вә кискенлекне һәр эшендә сизеп була иде".

Г.Бубый тарафыннан башланган әлеге яңалыклар, җәдиди үзгәртеп корулар көчәя барган саен, татар мөселманнары тормышына активрак үтеп керә башлый. Җомга һәм гает намазларында, башка дини йолаларны үткәргәндә хөтбә-вәгазьләрне татарча укуга игътибар арта. Шул ук вакытта татар телендә Коръән тәрҗемәләре, тәфсирләре, хәдисләр басылып чыга, хөтбә-вәгазь мәҗмугалары дөнья күрә. Шулай итеп, хәзерге татар әдәби теленең стилистик системасында шактый үзенчәлекле булган тагын бер социаль-функциональ стиль - илаһият өслүбе формалаша.

*(Дәвамы газетабызның киләсе санында.)*

**Фәрит МИҢНУЛЛИН,**
**филология фәннәре кандидаты,**
**Ш.Мәрҗани исемендәге**
**Тарих институтының өлкән**
**фәнни хезмәткәре**

# "Кайсыгызның кулы җылы?" хәйрия акциясе

***Кызганыч, ата-ана назыннан мәхрүм ятим сабыйлар саны шактый. Ислам диненда ятимнәргә зур урын бирелә. Изге Коръән һәм мөселман галимнәре дә аларга карата битараф булмаска чакыра.***



15 майдан 15 июньгә кадәр Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте "Татар радиосы" белән берлектә "Кайсыгызның кулы җылы?" хәйрия акциясен башлап җибәрә. Акция кысаларында Дәрвишләр бистәсендәге физик яктан зәгыйфь балалар интернат-йортына өлкәннәр өчен подгузниклар, гигиена чаралары һәм урын-җир кирәк-яраклары җыелачак. Әлеге интернат-йорт күп төрле тернәкләндерү чараларына ия булган учреждениеләрдән санала.

Интернатта психофизик тайпылыш күзәтелгән 200 инвалид бала тәрбияләнә, шуларның яртысы - ятимнәр, интернат аларның туган йортлары кебек. Бирегә бөтен республикадан 4 яшьтән алып 18 яшькә чаклы балалар кабул ителә. Интернат җитәкчелеге балаларны тиешенчә карау, кайгырту, укыту өчен кирәк булган шартларны тудырып килә. Әмма барлык чыгымнар өчен бюджетта каралган акча гына җитеп бетми, шунлыктан интернатка кулдан килгәнчә ярдәм күрсәтү сорала.

Ярдәм кулын сузарга теләкләре булган һәркем кирәкле әйберләрне Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 йорт адресы буенча урнашкан ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең хәйрия һәм ярдәм күрсәтү бүлегенә (3 нче кат, 4 нче бүлмә) тапшыра ала.

**Белешмәләр өчен телефон: +7 (843) 264-61-58 (Гөлнара Садыйкова).**




## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 19.05.12 | 2:54 | 4:24 | 13:02 | 18:19 | 20:57 | 22:27 |
| Якшәмбе | 20.05.12 | 2:52 | 4:22 | 13:02 | 18:20 | 20:59 | 22:29 |
| Дүшәмбе | 21.05.12 | 2:51 | 4:21 | 13:02 | 18:21 | 21:00 | 22:30 |
| Сишәмбе | 22.05.12 | 2:49 | 4:19 | 13:02 | 18:22 | 21:02 | 22:32 |
| Чәршәмбе | 23.05.12 | 2:48 | 4:18 | 13:02 | 18:23 | 21:04 | 22:34 |
| Пәнҗешәмбе | 24.05.12 | 2:46 | 4:16 | 13:02 | 18:24 | 21:05 | 22:35 |
| Җомга | 25.05.12 | 2:45 | 4:15 | 13:02 | 18:25 | 21:07 | 22:37 |
| Шимбә | 26.05.12 | 2:44 | 4:14 | 13:02 | 18:27 | 21:09 | 22:39 |



ООО «Ритуальные услуги»
Изготовление памятников и оград

ул. К.Насыри, 17, мечеть Аль-Марджани,
ул. 2-я Армавирская мечеть Нур-эль-Ислам,
ул. Мусина, 10, мечеть Булгар,
ул. Чистопольская, 1, мечеть Казан Нуры,
Оренбургский тракт, 193, мечеть Гадель,
ул. Мавлютова, 48, мечеть Ризван,
ул. Фучика, 52, мечеть Хузейфа,

Понедельник - пятница - с 9:00 до 18:00,
суббота - с 9:00 до 13:00.
**Тел.: 225-28-90, 293-25-61**

Основное производство находится на мусульманском кладбище при мечети Аль-Марджани на Мамадышском тракте.
Понедельник - с 9:00 до 13:00, со среды по воскресенье - с 9:00 до 18:00,
вторник - выходной.
**Тел.: 8-927-427-16-02, 293-45-93**

**На мусульманском кладбище захоронения ведутся по канонам Шариата.**
**Тел. 297-28-90**

Реклама

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №20 (137) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-534.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 17 май көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**